Республики Татарстан
Совет Татарско-Челнинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
Адрес: 423641с.Татарские Челны,
ул.Победы, д.3 А

Татарстан Республикасы Менделеев
муниципаль районы
Татар-Чаллысы авыл Советы
423641 Татар-Чаллысы авылы,
Җиңү ур.3 А нче йорт

Тел.(885549)3-62-23 E-mail: Tcn.Men@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 17 июненнән № 175

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында», 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы белән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Уставының 12 статьясы белән,

Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Менделеевские новости», «Менделеевск яңалыклары» район газеталарында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru - аны кабул иткән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Татар Чаллысы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Татар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгы Т.П.Кузнецова.